ҖОМГА
12 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 10 (5810)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ДАНЛЫКЛЫ ХӘРӘКӘТНЕҢ ГҮЗӘЛ ҖИҢҮЛӘРЕ ӨЧЕН

Партиябезнең XVIII нче съезды өченче бишьеллыкта елына 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү бурычын куйды. Бөек остазыбыз иптәш Сталин инициативасы буенча партиябез тарафыннан куелган бу зур һәм гаят мактаулы бурычны үтәү өчен колхозларда һәм совхозларда тагын да киңрәк җәелгән социалистик ярышта үткән елны яңа бер хәрәкәт барлыкка килде. Бу—бөртекле культураларның һәр гектарыннан 100 пот иген уңышы алу өчен көрәш.

Сталинград өлкәсе бригадирлары тарафыннан башланган бу данлыклы хәрәкәт соңгы вакытларда, бигрәк тә Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгылары мөрәҗәгатеннән соң, безнең Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында да тизлек белән җәелә башлады. Бик күп совхозларыбыз һәм колхозларыбыз, колхоз бригадалары һәм звенолары йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылдылар, бөртекле культураларның һәр гектарыннан быел йөз пот кына түгел, йөз ун, йөз егерме, йөз илле пот һәм аннан да артык итеп иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алдылар. Алар бу йөкләмәләрен үтәү өчен практик чаралар билгелиләр, язгы чәчүгә һәм аны үткәрүгә большевистик оешканлык белән хәзерлек алып баралар. Кайбер районнарда, мәсәлән, Калинин районында, үзләренә беркетелгән участкыларда бөртекле культураларның һәр гектарыннан алтмыш—җитмеш центнер иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алган звенолар бар. Алар бу йөкләмәләрен уңышлы итеп үтәячәкләренә нык ышанганлыкларын белдерәләр.

Йөзпотчылар хәрәкәте ул, авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм машиналардан максимум файдалану белән бер рәттән, туфракның уңыш бирү көчен арттыру өчен көрәш дигән сүз. Ә туфракның уңыш бирү көчен арттыру турыдан-туры ашламаларга һәм ул ашламалардан, беренче чиратта җирле ашламалардан, тулысынча һәм дөрес итеп файдалануга бәйләнгән.

Йөзпотчылар хәрәкәтенең инициаторлары Гуров һәм Козленков иптәшләр ашламалардан файдалануга нык әһәмият бирәләр. Алар барлык агрономия чаралары комплексын үткәрү, ашламалардан тулысынча файдалану нәтиҗәсендә, үткән елны үзләренең йөкләмәләрен арттырып үтәделәр, үзләренә беркетелгән участкыларда гектарыннан уртача 120 пот иген уңышы алдылар һәм быел 150 пот алуга ирешүне йөкләмә итеп алдылар.

Җирле ашламалар кулланып, туфракның уңыш бирү көчен күтәрү өчен Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында чиксез зур мөмкинлекләр бар. Җирле ашламалардан тиресне алыйк. Тәҗрибә станцияләренең һәм колхозларның тәҗрибәләренә караганда, пар сөрү вактында туфракка кертелгән һәрбер 4 тонна яхшы тирес шул елны чәчелгән арыш уңышын бер центнерга, ә аннан соң чәчелгән сабан культурасы уңышын ярты центнерга арттыра. Туфракка кертелгән яхшы тиреснең тәэсире дүрт-биш елга кадәр дәвам итүе дә шулай ук күп сыналган инде.

Җирле ашламалардан торфка да шулай ук бездә байлык зур. Тулы булмаган мәглүматларга караганда, Татарстан АССР да 120 миллион тонна чамасы торф барлыгы билгеле. Торф республикабызның һәрбер районында бар.

Күп кенә колхозлар торфтан ашлама төсендә файдаланып соңгы елларда иген уңышын күтәрүдә шактый зур уңышларга ирештеләр. Мәсәлән, Норлат районының „Строитель" колхозы торф белән ашлаган участкыларда уҗым культуралары уңышын башка участкылардагыга чагыштырганда 4—5 центнерга артыграк алып килә.

Кош тизәге, фекаль, көл, елга юшкыны һәм башка шундый ашламаларны да бездә бик күп итеп хәзерләргә мөмкинлек бар.

Җирле ашламалардан без ничек файдаланабыз соң? Дөресен әйтергә кирәк, тирестән дә, торфтан да һәм башка төр җирле ашламалардан да файдалану Татарстан АССР ның күп колхозларында һәм совхозларында канәгатьләнерлек булудан ерак тора әле.

Үткән елны бездә 7 миллион тонна чамасы тирес җыелган иде. Бу тиреснең бөтенесен дә басуга чыгарырга мөмкин иде. Ә фактта басуга бары 3 миллион тонна чамасы тирес чыгарылды. Кайбер районнар бу файдалы һәм арзан ашламадан файдалану эшенә аз әһәмият бирәләр. Мәсәлән, Алексеевский районы үткән елны басуга тирес чыгару планын 28 процент, Минзәлә районы—32 процент һәм Алабуга районы бары 37 процент үтәделәр. Үткән ел бу районнарда иген уңышын башка районнардагыга чагыштырганда шактый түбән алуларының төп сәбәбе, һич шиксез, әнә шунда. Алексеевский, Минзәлә һәм Алабуга районнары үткән елгы кимчелекләрне тагын кабатлыйлар, аларда басуга тирес чыгару эше быел да бик акрын бара.

Торф хәзерләү һәм аны ашлама итеп файдалану буенча да бездә эш яхшылап оештырылмаган. Башка төр җирле ашламалардан файдалану эше дә мактарлык куелмаган.

Кышкы чор җирле ашламалар хәзерләү өчен иң уңайлы вакыт булып хисаплана. Колхоз һәм совхоз җитәкчеләре бу чордан нык файдаланырга тиешләр. Язгы чәчүгә хәзерлек буенча башка эшләрне киң җәелдерү белән бергә җирле ашламаларны күп итеп хәзерләү, алардан дөрес һәм тулысынча файдалану тәэмин ителергә тиеш. Киләсе язда һәм җәй көнендә тирес белән ашланырга тиеш участкылар хәзердән үк билгеләнергә, басуга тирес чыгару, кош тизәге, фекаль һәм компост ашлама хәзерләү быел 100 пот иген уңышы алуны тәэмин итәрлек итеп оештырылырга тиеш.

Йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылып, елына 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү көрәшенә якыннан катнашу—һәрбер колхозның һәм совхозның, һәрбер бригада һәм звеноның иң мактаулы бурычы. Бу хәрәкәт тагын да киңрәк колач белән алга барсын өчен аңар партия һәм совет оешмалары тарафыннан, беренче чиратта, җир органнары тарафыннан җитәкчелекне тәэмин итәргә кирәк. Югары иген уңышы алу буенча барлык тәҗрибәләрдән киң күләмдә файдалануны оештырыйк, йөзпотчылар хәрәкәтен массовой хәрәкәткә тизрәк әйләндерик.



„Седов" бозваткычы дрейфенең еллыгына карата. РӘСЕМДӘ: „Седов" бозваткычы Лаптев диңгезе бозлары арасында. (Тарихи дрейфкә бер ай кала, 1937 нче елның сентябрь ае ахрында төшерелгән рәсем). А. Лесс фотосы (Союзфото).

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Медицинаның аеруча хезмәт күрсәткән работникларын СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләү турында

Хөкүмәт заданиесен үз-үзләрен аямыйча һәм уңышлы үтәүләре өчен бүләкләргә:

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән

1. Исаак Иосифович Рогозинны.
2. Владимир Яковлевич Эдельманны.

„Почет билгесе" ордены белән

1. Анатолий Борисович Александровскийны.

„Аеруча хезмәт күрсәткән өчен" медале белән

1. Петр Михайлович Андриановны.
2. Мария Матвеевна Бочинаны.
3. Роза Александровна Брайнинаны.
4. Евдокия Абросимовна Дворянкинаны.
5. Елена Васильевна Кашинаны.
6. Анна Игнатьевна Каранецкаяны.
7. Александр Иванович Малининны.
8. Анастасия Александровна Семенованы.
9. Валентина Сергеевна Терещенконы.
10. Сергей Иванович Федоровны.
11. Анна Васильевна Чистоповаланы.
12. Иван Иванович Шатровны.
13. Степан Яковлевич Яковлевны.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
10 гыйнвар, 1940 ел.

„Седов" бозваткычы янында бозның ярылуы

„Седов" бозваткычы борты, 10 гыйнвар. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән радио). Кичә „Седов" хәрәкәте районында көн болытлы булды. Һаваның температурасы иртән — плюс 1,2 градус иде, төн уртасында ул минус 1,7 градуска кадәр төште. 5—6 балл көчендә көньяк җиле исте. Элекке кебек үк болытларның куе булуы пароходның координатларын билгеләүгә комачаулык тудырды. Көндез сул борттан 50 метр ераклыкта юка бозның ярылганлыгы күренде һәм кичкә таба бу ярык гаят киңәйде. Ярык төньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка таба булган юнәлештә башланып, көньяк өлештә күзгә күренерлек ераклыкта тәмам була. Горизонтның төрле урыннарында күкнең төсенә карап бозсыз су бар дип уйларга мөмкин. „Седов" бозваткычы белән бергә күп айлар буена хәрәкәт иткән гаят зур боз кырыннан киңлеге 50 метр чамасы һәм озынлыгы 100 метр чамасы булган боз кисәге генә калды. Боз ярылган урыннан арырак күп еллар буена яшәп килә торган зур боз кырлары башлана. Алар „Седов" урнашкан урынны тыгыз боҗра төсендә чолгап алганнар. Алар артында пароходтан көньякка таба „И. Сталин" бозваткычының утлары ачык булып күренеп тора. Без еш кына бу утларга карыйбыз. Алар безнең бозлар тоткынлыгыннан тизлектә котылачагыбызның хәбәрчеләре.

Пароходта барсы да яхшы. Һәр кем сәламәт һәм күтәренке күңелле.

Н. Бекасов.

Хезмәт җитештерүчәнлегенең 5 еллык планын 4 елда үтик

Күп станокларда эшләүчеләр

Күп станокта эшләүчеләр хәрәкәте Максим Горький исемендәге заводта киң колач алды.

Токарь иптәш Ф. Е. Коньков өч токарьный станокта эшләүгә күчте. Ул беренче көннәрдә үк уңышлы нәтиҗәләргә иреште. Иптәш Коньков хәзер һәр станокка бирелгән норманы 112,5 процент итеп үти. Ул детальне башта бер станокка куеп, аны ходка җибәрә, аннан соң икенчесенә һәм өченчесенә күчә. Иптәш Коньков эш вактының һәрбер секундын тулысынча файдалана. Ул суднолар төзү промышленносты наркоматы тарафыннан кыйммәтле әйбер белән бүләкләнде.

Токарьлардан П. З. Королева, М. Е. Кириллов, Насыйров һәм башка иптәшләр дә икешәр станокта эшләүгә күчтеләр, норманы тулысынча үтиләр.

Заводта бер үк вакытта берничә профессияне башкару методы да кулланыла. Мәсәлән, җыючылар бригадасы (бригадиры иптәш П. Гущин) җыю эшен үтәү белән бергә, кисү һ. б. эшләрне дә башкара. Элек бу эшләрне башкарган вакытта җыючыларга еш кына буш торырга туры килә иде. Хәзер бу бригаданың барлык эшчеләре эш белән тулысынча тәэмин ителгәннәр. Күп профессияләрне бер үк вакытта үтәү нәтиҗәсендә иптәш Гущин бригадасы җыю эшендә беренчелекне алды һәм норманы 160 процент итеп үти. Иптәш Гущин хәзер ай саен мең сумнан артык хезмәт хакы ала.

Иптәш Комков җитәкчелегендәге җыючылар бригадасы да шундый ук методларны куллануга керешә.

ЗУР ҖИҢҮ

Серго Орджоникидзе исемендәге заводта производство процессларын яхшырту өстендә эшләп, без, технолог Маркушин белән берлектә, гофр калаен кул ярдәме белән калыплауны механикалаштырылган авыр чүкеч белән калыплау турында такдим керттек. Бу такдимне тормышка ашыру хезмәтнең җитештерүчәнлеген 240 тапкыр арттырды.

Хәзер без тоташтыру узелларындагы винт урыннарының эчләрен яхшырту турындагы такдимне производствога бирергә хәзерләнәбез. Бу, винт урыннарын иң уңайсыз урыннарда да механик юл белән тишү һәм шомарту мөмкинлеген бирәчәк, хезмәтнең җитештерүчәнлеген берничә тапкырга арттырачак.

Быел без рационаллаштыру эшенә эшчеләрнең һәм инженер-техник работникларның киң массаларын тартып, заводка 100 мең сумнан артык экономия бирәчәкбез.

Без быел рационализаторлар һәм уйлап табучылар кабинеты ачарга хәзерләнәбез. Анда җиһазландырылган эш урыннары булачак, консультация эшләре дә шушында тупланачак.

Технолог *В. Прозоров.*

МИНЕМ ТАКДИМНӘРЕМ

1939 нчы елны мин рационаллаштыру буенча производствога 11 такдим керттем. Аларның 6 сы тормышка ашты инде. Калганнары өстендә өйрәнү - тикшеренү эшләре алып барыла. Минем тарафтан кертелгән такдимнәр производствога 135 мең сум чамасы экономия бирделәр.

Москва инструменталь заводы коллективының мөрәҗәгате безнең алга хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча гаят җаваплы бурычлар куя. Инструметальщикларның чакыруына эш белән җавап бирергә тиешбез.

Мастер *В. Афонин.*

АЛДЫНГЫЛЫКНЫ БИРМӘБЕЗ

Тымытык районы финанс туплау буенча берничә елдан бирле алдынгы сафта бара. Ул 1938 нче елда финанс туплау планын республикада беренче булып төгәлләве өчен Татарстан Совнаркомының беренче бүләген алган иде. Район 1939 нчы елда да алдынгылыкны бирмәде. Заем облигацияләрен урнаштыру бик яхшы нәтиҗәләр белән тәмамланды.

1940 нчы елның 1 нче гыйнварына барлык подписка сумасының 99 проценты җыелып алынды.

Вкладлар туплау буенча да район бик яхшы нәтиҗәләргә ирešте. 1939 нчы елның 1 нче гыйнварына вкладлар калдыгы 103 мең сум булса, 1940 нчы елның 1 нче гыйнварына 181 мең сум тәшкил итә. Вкладлар туплауның еллык планы 119 процентка үтәлде.

Район саклык кассасының Чуар Абдул авылындагы бүлекчәсендә эшләүче иптәш Исхаков вкладлар туплау эшендә аеруча тырышып эшләде. Бу бүлекчәдә еллык план 162 процент итеп үтәлде. Район үзәгендәге кассада контролер булып эшләүче Кадыйров, кассир Алчинов иптәшләр еллык планны 118 процент итеп үтәделәр.

Саклык кассасының барлык работниклары 1940 нчы елда финанс туплау планын уңышлы үтәү өчен үзара социалистик ярыш договоры төзеделәр һәм конкрет йөкләмәләр алдылар.

Диаров.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

10 нчы гыйнварда фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмады. Фронт участкыларында разведчикларның эзләнүләре һәм урны-урны белән артиллерия атышы булды.

Һава начар булганлыктан безнең авиация бары тик разведка очышлары гына үткәрде.

Күптән түгел конфликт булган районда Монголия Халык Республикасы белән Манчжоу-Го арасында чикне төгәл билгеләү буенча катнаш комиссиянең бергәләп белдерүе

Катнаш комиссиянең унынчы утырышы 1940 нчы елның 10 нчы гыйнварында Харбин шәһәрендә, Совет—Монголия делегациясе урнашкан „Ямато" отелендә, Монголия Халык Республикасы хөкүмәтенең уполномоченные Джамсарон әфәнде председательлегендә булды. Карта буенча чикне төгәл билгеләү мәсьәләсен тикшерү дәвам итте. Алдагы утырыш 13 нче гыйнварда булачак. (ТАСС).

ХРОНИКА

Иптәш М. М. Кагановичның башка эшкә күчүе сәбәпле һәм аны авиация промышленносты наркомы хезмәтеннән азат итү уңае белән, авиация промышленносты наркомы итеп иптәш А. И. Шахурин билгеләнде, самолет төзелеше буенча нарком урынбасарлары итеп А. С. Яковлев һәм П. А. Воронин иптәшләр билгеләнде.

В. В. МАЯКОВСКИЙ ИСТӘЛЕГЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ

СССР Халык Комиссарлары Советы В. В. Маяковский истәлеген мәңгеләштерү буенча бөтен Союз күләмендә комитет төзергә карар бирде. Бөтенсоюз комитетының председателе итеп Н. Н. Асеев, председатель урынбасарлары итеп П. А. Тюркин һәм А. А. Фадеев, җаваплы секретарь итеп В. О. Перцов иптәшләр расланды. Бөтенсоюз комитетына членлыкка А. Я. Вышинский, Л. З. Мехлис, Г. М. Маленков, Е. М. Ярославский, П. Н. Поспелов, Т. И. Антропов, С. И. Кирсанов, А. Т. Твардовский, Симон Чиковани, Н. П. Бажан, Мөхәммәдҗан Рәхими, Абдулла Таҗибаев, Наири Зарьян, Рәсүл Рза, С. А. Трегуб, Помма Нурбердиев, Шәйхи Маннур, Н. П. Охлопков, В. И. Лебедев-Кумач, В. А. Луговской, А. А. Дейника, М. М. Штраух, И. Г. Большаков, П. И. Чагин, М. Б. Храпченко, С. В. Кафтанов, Г. Я. Ярцев, Л. В. Маяковская, А. С. Езерская, Л. Я. Ровенский, И. С. Тихонов һәм А. А. Прокофьев иптәшләр расландылар.

Бөтенсоюз комитетына В. В. Маяковский истәлеген мәңгеләштерү һәм аның иҗадын СССР халыклары арасында популярләштерү буенча чаралар планын ун көн срок эчендә карарга һәм СССР хөкүмәте раславына кертергә тапшырылды. (ТАСС).

ХӘРӘКӘТТӘГЕ КАРАБТА 26 АЙ

ХӘРӘКӘТНЕҢ БАШЛАНУЫ

1937 нче елның 23 нче октябрендә „Седов“, „Садко“ һәм „Малыгин“ бозваткыч пароходлары төньяк киңлекнең 75 градус 21 минутында һәм көнчыгыш озынлыкның 132 градус 15 минутында авыр бозлар арасында кышларга калдылар. Бозлар хәрәкәте аларны башта төньяк юнәлештә 133 нче меридиан буйлап, аннары төньяк-көнчыгышка таба алып китте.

Караңгы Котып төне башланды. „Седов“, „Садко“ һәм „Малыгин“ командалары, карабларны һәм кешеләрне саклау өчен, стихиягә каршы героик көрәшеп, бөтен көчләрен биреп, авыр вахтаны ныклык белән алып бардылар. Карабларның өчесендә дә кызыклы һәм кыйммәтле фәнни күзәтүләр бер генә сәгатькә дә тукталмады.

1938 нче елның 2 нче мартында караблар хәрәкәтнең иң кырыйдагы көнчыгыш ноктасына—көнчыгыш озынлыкның 153 градус 26 минутына кадәр җиттеләр. Жанетта атавыннан төньякта хәрәкәтнең юнәлеше кинәт үзгәрде: боз хәрәкәте бозваткыч пароходларны төньяк-көнбатышка таба алып китте. Тиздән алар материк ярындагы сайлыктан тирән океанга чыктылар. Төньяк Боз океанының мәңге хәрәкәт итүче бозлары белән кысылган карабларның бу бозлар белән берлектә көнбатышка таба еракка китәчәкләре ачык иде.

Хәрәкәттәге „Седов“, „Садко“ һәм „Малыгин“ карабларында 217 кеше бар иде. Хәрәкәт вакытында, билгеле, мондый зур состав кирәк булмады. Хөкүмәт бозваткычларда аларны саклау һәм фәнни күзәтүләр өчен кирәк булган нык чикләнгән санда гына кешеләр калдырырга карар бирде.

Хәрәкәттәге карабларга Папанин экспедициясен Төньяк Котып янындагы боз өстенә төшерүдә катнашкан өч авыр самолет җибәрелде. Алексеев, Головин һәм Орлов иптәшләр Сталин заданиесен бик яхшы башкарып чыктылар: хәрәкәттәге бозваткычлардан алар 184 кешене Зур Җиргә китереп куйдылар һәм карабларда калган морякларны ике елдан артыкка җитәрлек азык, елы киемнәр, ит, яшелчә һәм төрле туклыклы азыклар белән тәэмин иттеләр.

„БӘХЕТЛЕ КЫШЛАГЫЗ!“

...Бозваткыч пароходлар төньякка таба хәрәкәт итүне дәвам иттерделәр. Аларның командалары, фәнни күзәтүләрне туктатмыйча, стихиягә каршы героик көрәш алып бардылар.

1938 нче елның котып язы башланды. Бозлар арасында хәрәкәт итүче карабларга ярдәмгә Арктика флотының карт бозваткычы „Ермак“ җибәрелә. Бозлар арасында иректе йөзүдә рекорд биреп, „Ермак“ 1938 нче елның 28 нче августында, 83 градус 06 минут киңлектә, хәрәкәттәге бозваткыч пароходлар янына килеп җитте. Авыр бозларга каршы нык һәм озак көрәштән соң „Ермак“ „Садко“ны һәм „Малыгин“ны бозлар тоткынлыгыннан алып чыга алды. „Седов“ны коткаруга булган омтылыш нәтиҗәсез тәгәлләнде.

Үзлегеннән хәрәкәт итә алмаучы „Седов“ны буксирга тагып тарттыру чиктән тыш авыр булды. Зарарланган руль карабны кискен рәвештә кырыйга янтайтты. Җиде дюймлы корыч арканнар өзелде. „Ермак“ бу авыр эшне үти алмады. Аның ишү валлары сындылар һәм винтлары белән берлектә океан төбенә киттеләр. „Ермак“ куәтенең өчтән ике өлешен югалтты, бер машина белән генә „Седов“ны буксирга алырга булдыра алмады. „Седов“ны хәрәкәттәге фәнни-тикшерү станциясе сыйфатында бозлар арасында хәрәкәт итәргә калдырырга карар бирелде. „Седов“ның бозлар арасында кышларга калуы турындагы хәбәр „Ермак“ка ишетелү белән үк, „Ермак“ командасыннан 40 тан артык моряк шунда ук „Седов“ка күчәргә теләкләре барлыкны белдерделәр. Ләкин хәрәкәттәге карабка өстәмә рәвештә бары 6 кеше кирәк иде. Яхшыларның иң яхшылары сайлап алынды. Өлкән механик орденлы Дмитрий Григорьевич **Трофимов**, радист Николай Михайлович **Бекасов**, стахановчы кочегар Иван Иванович **Гетман**, повар—моряк Павел Власович **Мегер**, машинист Иосиф Маркович **Недзвецкий** һәм матрос Ефрем Иванович **Гаманков** иптәшләр „Седов“ бортына күчтеләр. „Седов“ командасыннан икенче кышлауга 9 кеше калды: „Седов“ ның капитаны Константин Сергеевич **Бадигин**, капитан ярдәмчесе инженер Андрей Георгиевич **Ефремов**, радист Александр Александрович **Полянский**, врач Александр Петрович **Соболевский**, боцман Дмитрий Прокофьевич **Буторин**, стахановчы машинист Николай Сергеевич **Шарыпов**, икенче механик Сергей Дмитриевич **Токарев**, өченче механик Всеволод Степанович **Алферов** һәм яш галим гидрограф Виктор Харлампиевич **Буйницкий**.

30 нчы августта „Седов“ ның мачтында:—„Хәерле юл!“ дигән вымпел күренде.

— Бәхетле кышлагыз!, — дип җавап бирде „Ермак“.

Гудоклар аркылы „Седов“ белән саубуллашканнан соң, „Садко“ һәм „Малыгин“ белән берлектә „Ермак“, авыр бозлар арасыннан көньякка таба юл тотты. Аз гына сандагы моряклары белән героик пароход Төньяк Боз океаны бозлары арасында калды.

3 нче сентябрьдә иптәш Сталинга һәм аның иң якын көрәштәшләренә „Седов“ ның капитаны Бадигин һәм помполиты Трофимов иптәшләр түбәндәге телеграмманы җибәрделәр:

„Без, Үзәк Котып бассейнында хәрәкәт итәргә калган „Седов“ ның экипажы, Төньяк Боз океанының тикшерелмәгән киңлекләрендә беренчеләр булу өчен безгә күрсәтелгән ышанычны бөек хөрмәт дип саныйбыз. Без, сөекле партиябез тарафыннан, сөеклебез иптәш Сталин, Сезнең тарафтан тәрбияләнгән кешеләр, котып төне бозлары арасында бөек Ватаныбызның ал байрагын горурлык белән намуслы рәвештә алып барырбыз. Үзәк Котып бассейнын тикшерү буенча өстебезгә йөкләнгән эшне үтәү өчен барлык көчләребезне, белемебезне һәм тәҗрибәбезне бирербез, совет фәненең яңа җиңүләре өчен горурлык белән көрәшербез, үзебезгә ышанып тапшырылган пароходны саклау өчен барын да эшләрбез. Без язмышыбыз өчен бөтенләй тыныч, чөнки без, партиябезнең, хөкүмәтебезнең һәм бөтен халкыбызның безнең турыда кайгыртучанлык күрсәтәчәкләренә ышанабыз.

Иптәш Сталин, Ватанабыз тарафыннан безгә күрсәтелгән бөек хөрмәтне һәм ышанычны аклау өчен 15 совет патриоты барсын да эшләр, дип Сезне ышандырабыз“.

Шул ук 1938 нче елның Котып көзендә „Седов“ ны бозлар арасыннан алып чыгу өчен тагын бер тапкыр омтылыш ясалды. Новосибирск атауларыннан төньякка таба (хәрәкәттәге караб ул чагында шунда иде) Арктика флоты флагманы „И. Сталин“ линейней бозваткычы үзенең котып рейсенә юнәлде. Лаптевлар диңгезенең төньяк өлешендә карабны авыр бозлар каршы алды. Ул аларны үзенең авырлыгы белән ватып, гаят зур кыенлыклар белән төньякка таба юл салды. Флагман артыннан бозкискеч „Литке“ барды, ул „Седов“ ны буксирга алырга тиеш иде.

Шул арада котып караңгылыгы башланды. Бозваткыч үткән юл яңадан бозлар белән капланды. Буран башланды. Океанның чиксез бушлыклары калын кар катлавы белән капланды. Озакламый бер нәрсә дә күренми башлады. Катлаулы операциянең барышын игтибар белән күзәтеп торучы иптәш Сталин, Арктика флоты флагманының капитаны иптәш В. И. Воронинга уйламыйча рисковать итмәскә һәм беренче куркыныч булу белән үк көньякка таба юл тотарга киңәш бирде.

Котыпта йөзү өчен чиктән тыш соң булган бу вакытта „И. Сталин“ бозваткычы 82 нче параллельгә җитте. „Седов“ янына барып җитәргә берничә уннарча миль калды. Ләкин бу соңгы мильләр хәтта Арктиканың „И. Сталин“ бозваткычы кебек куәтле пароходы өчен дә үтә алмаслык булдылар. Сталинның акыллы киңәше белән, бозваткыч көньякка таба юл тотты...

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

РАЙКОМНЫҢ БУЛЫШЛЫГЫ ҖИТӘРЛЕК ТҮГЕЛ

Питрәч районында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н яхшы өйрәнүчеләр бар. Мәсәлән, „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ дигән медаль белән бүләкләнгән алдынгы укытучы, яшь коммунист иптәш Мартьянов үзенең теоретик белемен күтәрү өстендә өзлексез эшли. Ул лекцияләргә һәм консультацияләргә системалы рәвештә йөри. Шәле авылындагы урта мәктәпнең уку-укыту эшләре бүлеге мөдире иптәш Алишов (партиясез) марксизм-ленинизм классиклары әсәрләреннән файдаланып, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне тәмамлап, яңадан тирәнтен өйрәнергә керешне. „Хезмәт Кызыл Байрагы“ ордены белән бүләкләнгән укытучы иптәш Кутасова да үзенең политик белемен күтәрү өстендә тырышып эшли.

Ләкин ВКП(б) райкомы бу иптәшләрне белми, партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләрнең тәҗрибәләрен уртаклашуны оештырмый, марксизм-ленинизмны өйрәнүче коммунистларга, комсомолецларга һәм совет интеллигенциясенә җитәрлек булышлык күрсәтми.

Күп кенә авылларда партия пропагандасының куелышы канәгатьләнерлек түгел. Кон авылындагы башлангыч партоешма соңгы вакытларда 12 комсомолецны партия сафларына кабул итте. Ләкин яшь коммунистларның күбесе, мәсәлән, Галиуллин, Г. Галиева, Г. Хәлимев, С. Ильясова, Гыйззәтов, Ахунов һәм Салахиев иптәшләр партия тарихын өйрәнүгә тартылмаганнар. Партия оешмасы секретаре иптәш Мөхәмәтҗанов әле үзе дә партия тарихын ныклап өйрәнүгә керешмәгән.

Шәле авылы партоешмасында коммунистлардан Сәйфеттинев, Таҗиев, Әхметҗанов, Вәлиуллин һәм Галимбиков иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү эшенә керешмәгәннәр. Партоешма секретаре иптәш Җиһаншина партия пропагандасын юлга салу турында кайгыртмый. Комсомолецлар арасында да партия тарихын өйрәнү эше тиешенчә оештырылмаган. *Х. Гарипов.*

ДИНГӘ КАРШЫ ПРОПАГАНДА ЭШЕ ЯХШЫ КУЕЛГАН

Дөбъяз районында дингә каршы пропаганда эше үрнәк булырлык итеп оештырылган. ВКП(б) ның Дөбъяз райкомы дингә каршы популяр лекцияләр уку өчен хәзерлекле коммунистлардан, комсомолецлардан 28 кешене лектор итеп раслады. Лекторлар аерым участкыларга беркетелделәр, аларга лекцияләрнең тематикалары бирелде. Алар белән ике тапкыр фикер алышу киңәшмәсе үткәрелде. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлек вактында дингә каршы темада 30 тапкыр лекция һәм 178 тапкыр доклад куелды. Аларны 10 меңнән артык кеше тыңлады.

Агитаторлар Лениннең „Социализм һәм дин“ дигән әсәре буенча һәм „Ленин дин турында“ дигән темада беседалар алып бардылар. Лекторлар Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмаларын оешу ягыннан ныгытуда якыннан торып ярдәм итәләр.

Әлдермеш авылындагы оешмага лектор иптәш С. Салихова җитәкчелек итә. Бу авылда 3 урында дингә каршы түгәрәк оештырылган.

Районда 45 урында Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмалары бар. Алар 1.219 кешене берләштерәләр. ВКП(б) ның Дөбъяз райкомы райком работникларыннан һәм урындагы иптәшләрдән 50 кешене Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмаларын ныгыту һәм яңа оешмалар оештыру буенча булышлык күрсәтү өчен авылларга беркетте. *Х. Галиев.*

Шәһәр Советы җирле промышленность бүлеге мөдире иптәш Шәех Исламов үзенең квартирасында үзлегеннән партия тарихының „Кыскача курсы“н өйрәнү өстендә. И. Галиев фотосы.

ТҮБӘНГЕ ЗВЕНО ТҮГӘРӘКЛӘРЕ

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н түбәнге звено буенча оештырылган ике түгәрәккә җитәкчелек итү эше миңа тапшырылды.

Мин занятиеләрне айга 3 тапкыр үткәрәм. Хәзер без өченче этапны өйрәнә башладык. Беренче этап буенча 10 һәм икенче этап буенча 7 занятие үткәрелде. Шулай ук икенче этап буенча 4 тапкыр групповой һәм 2 тапкыр индивидуаль консультацияләр үткәрдем, конспект төзүдә ярдәм оештырдым.

Занятиеләр һәм консультацияләр билгеләнгән вакытта үткәреләләр. Мин аларда художество әдәбиятыннан, карталардан, альбомнардан нык файдаланам; түгәрәктә өйрәнүчеләрне халыкара хәл мәсьәләләре белән системалы рәвештә таныштырып торам. Болар минем эшемә зур ярдәм итәләр.

Занятиеләр иптәшләрчә беседа һәм дискуссия юлы белән алып барыла. Партия тарихын өйрәнүдә бер-берсенең җитешсез якларын күрсәтәләр, аларны бергәләшеп төзәтү чарасын күрәләр. Иң соңыннан мин аларның сөйләүләрен ачыкландырып һәм тулыландырып, йомгак ясыйм, алдагы занятиеләр өчен заданиеләр бирәм.

Түгәрәктә өйрәнүче 28 иптәштән 25 кеше сайлаулар вактында агитатор булып эшләде, 9 кеше хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына депутат итеп сайланды. М. Шәмсеттинев һәм М. Хәсәнев иптәшләр колхоз председательләре булып эшлиләр. Алар җитәкчелек итә торган колхозлар районда алдынгылар сафында торалар. Иптәш Шәмсеттинев җитәкчелек итә торган „Большевик“ колхозы барлык политик-хуҗалык эшләрен районда алдынгы булып үтәп килә. Дәүләткә ашлык тапшыру, МТС ка натуралата түләү һәм финанс туплау планы срогыннан элек үтәлде. Колхозда заем взнослары кертү 15 нче декабрьгә 100 процент тәгәлләнде. Иптәш Шәмсеттинев авыл советына депутат итеп сайланды.

Түгәрәкләр эшендә кимчелекләр дә бар әле. Түгәрәк занятиеләренә йөреш 90 проценттан артмый. Азнакай авылында партиянең башлангыч оешмасы секретаре иптәш Фәхретдинов түгәрәк эшендәге кимчелекләрне бетерүгә булышлык күрсәтми, занятиеләргә хәзерләнеп килмәүчеләргә карата бер нинди чара күрми. Бу кимчелекләр, һич шиксез, бетерелергә тиеш. *М. Насруллин.*

ВКП(б) ның Азнакай райкомы пропагандисты

Совет кешесенең бәхте

П. П. ШИРШОВ
Советлар Союзы Герое

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходының хәрәкәтен бөтен совет халкы зур игтибар белән күзәтеп торды. Аның бортында унбиш батыр моряк 26 айдан артык вакыт буена мактаулы Сталинчыл вахтада тордылар.

Седовчыларның котып бассейнының үзәк өлешендәге фәнни күзәтүләре планетабызның иң кызыклы өлкәләреннән берсе турында фәнгә бик кыйммәтле мәглүматлар бирәләр. Бу күзәтүләр теоретик яктан гаят әһәмиятле булу белән генә калмыйлар. Алар Төньяк морякларына үзләренең карабларын Төньяк диңгез юлы трассасы буйлап йөртергә ярдәм итәрләр, Арктика морякларының даими дошм ннары булган бозларга каршы көрәш алып баруда котыпчыларга булышлык итәрләр.

Седовчылар үз-үзләрен аямыйча эшләделәр, үзләренә тапшырылган фәнни эшләр программасын арттырып үтәделәр. Кыенлыкларга, бозларның кысуларына, көчле давылларга һәм рәхимсез салкыннарга карамастан, алар җәен дә, кышын да, котып төннәрендә дә, арктика җәенең томанлы көннәрендә дә планлы һәм системалы рәвештә киң фәнни тикшерүләр алып бардылар. Башланган эшне һәр вакыт ахрынача илтеп җиткерүче һәм һичбер төрле кыенлыклардан курыкмаучы совет кешеләренең гүзәл үзенчәлекләре монда ачык күренде.

„Седов“ ның котыпчы унбиш морягы—алар гади совет кешеләре. Алар бу озак һәм кыен фәнни экспедициягә махсус хәзерләнмәделәр. Караб экипажы членнары уртача 28—30 яштәге кешеләр. Алар барсы да Совет заманында үскәннәр, алар Совет флоты мәктәбен үткән кешеләр. Алар барсы да большевиклар партиясе, Ленин—Сталин комсомолы тәрбияләгән кешеләр.

Һәр төрле куркынычларга каршы көрәштә батырлык, үз-үзеңне аямаучанлык, кыюлык — совет халкында партия тарафыннан тәрбияләнә торган бу югары мораль сыйфатлар барсы да „Седов“ коллективының көндәлек эшләрендә бик яхшы күренәләр. Аларның большевистик омтылышын бер нинди киртәләр дә сындыра алмадылар. Котып морякларының Сталинчыл дуслык белән берләшкән ныклы коллективы һәр вакыт бөек Ватан белән бер тормышта яшәде. Ватанның, партиянең, бөек Сталинның аларны бәхетсезлектә калдырмаячакларын һәм кирәк булган вакытта үз улларына куәтле ярдәм кулларын сузачакларын седовчылар белделәр.

„Седов“ның героик эпопеясе—ул илебезнең тарихында лаеклы урын алачак, югары дәрәҗәдәге фәнни батырлык. „Седов“ның хәрәкәте башлану белән үк аны иптәш Сталин күзәтеп барды. Иосиф Виссарионович хәрәкәттәге карабта тормышның ничек баруы белән һәр вакыт кызыксынды, седовчыларның фәнни эшләре турында сорашты, аларның күңелләрен күтәрде, аларны үз-үзләрен аямыйча эшләүгә рухландырды.

1938 нче елның язында Лаптевлар диңгезе бозларында бер карван булып хәрәкәт иткән өч бозваткыч пароходның бортында 217 кеше бар иде. Хәрәкәттәге караванга, иптәш Сталин такдиме буенча, Москвадан 4 моторлы өч һава карабы җибәрелде. Аларны Алексеев, Головин һәм Орлов иптәшләр алып бардылар. Самолетлар хәрәкәттәге пароходлардан 184 кешене алып чыктылар һәм калган 33 морякны барлык кирәк-яраклар белән тәэмин иттеләр.

1938 нче елның җәендә, шулай ук турыдан-туры иптәш Сталин күрсәтүе буенча, хәрәкәттәге карабларны бозлар тоткынлыгыннан чыгару омтылышы булды. „Седов“ның руле зарарланганлыктан ул „Ермак“ артыннан бара алмады һәм Төньяк Боз океанында хәрәкәт итәргә калды. „Седов“ хәрәкәттәге фәнни-тикшерү станциясе булып әверелде.

Бер кадәр соңырак, тагын да Иосиф Виссарионович күрсәтмәсе буенча, „Седов“ка Арктика флотының флагман бозваткычы „И. Сталин“ җибәрелде. Иосиф Виссарионович, бозваткычның экипажы уйламыйча рисковать итмәсен дип һәм кышларга калу куркынычлы булса, кичекмәстән кире кайтсын дип кисәтеп куйды. Иптәш Сталинның бу акыллы кисәтүе Төньяк диңгез юлы баш идарәсенә кыен диңгез операциясен дөрес оештырырга ярдәм итте. Флагман карабы экипажы кулыннан килгәннең бөтенесен эшләде. Бозваткыч „Седов“ка якынлашкан иде инде, ләкин шуннан соң үтә алмаслык бозларга очрады һәм көньякка борылды.

Седовчылар Төньяк Боз океанында тырышып эшләүләрен дәвам иттерделәр. Алар бозга каршы көрәшүдә яхшы тәҗрибә тупладылар һәм барлык куркынычлы хәлләрдән намус белән чыктылар.

Хәрәкәттәге карабның экипажы бозлар арасында елдан артык вакыт үткәрде. Иптәшләрнең бер өлешен генә булса да алмаштыру өчен „Седов“ка һава экспедициясе җибәрергә дигән такдим туды. Седовчылар бу турыда белгәч, алар үзләре турында кайгырткан өчен Сталин һәм Молотов иптәшләргә кайнар рәхмәт белдерделәр һәм бөтен экипажны хәрәкәтнең ахрына кадәр карабта калдыруны сорап хөкүмәткә мөраҗәгат иттеләр.

Хөкүмәт героик моряларның соравын канәгатьләндерде. Шул ук вакытта иптәш Сталин алар өчен авыр самолетны хәзер тотарга киңәш бирде. 1939 нчы елның язынннан бирле Рудольф атавында очучы Орловның 4 моторлы самолеты тора. Ул, „Седов“ка ярдәмгә очарга һәр вакыт хәзер торган хәлдә, хәрәкәтнең ахрына кадәр Седов вахтасын алып бара.

Капитализм дөньясындагы котыпчыларның һәр вакыт юлдашлары булган куркулар һәм каушаулар седовчыларга чит нәрсә булдылар... Англиянең батыр котыпчысы капитан Скотт, 1912 нче елны Көньяк котыптан кайтканда, үзенең юлдашлары белән бергә ачлыктан һәм хәлсезлектән үлде. Көньяк котыпка экспедиция вактында коточкыч сыналуларны башыннан кичергән, берничә тапкырлар үлем алдында калган бу батыр кешене ялгызлык хисе, үз якыннарының язмышы өчен курку борчыды.

Аның соңгы язмалары өметсезлек трагизмы белән тулган. Аларның берсендә Скотт болай дип язган:

„... Без бик күңелсез урында һәлак булып барабыз. Бу хат бәлки табылыр һәм сезгә җибәрелер дигән өмет белән сезгә саубуллашу хаты язам. Әйтәсе килгән нәрсә шул, минем тол калачак хатыныма һәм ятим калачак улыма ярдәм итүегезне телим...

Мин үземнең бәхетсез баламны, Уилсон хатынын, Эдгард Эванс та үзенең хатынын бик аяныч хәлдә калдырабыз. Аларның хокукларын яклау өчен мөмкин булганның бөтенесен эшләгез. Бәхил булыгыз...

Кадерле дустым, үлгәндә мин сездән минем хатыныма һәм балама яхшылык итүегезне үтенәм. Әгәр дә дәүләт эшләргә теләмәсә, малаема тормышта сез ярдәм итегез...“.

Менә үлеп баручы капитан Скотт кулы белән язылган көндәлектәге соңгы язма: „Ходай хакы өчен безнең якыннарыбызны ташламагыз...“.

Капитан Скотт язмыш кулына ташланды. Ул үзенең фәнни бөек эшләрен Англия өчен эшләгән иде, ә Англия үзенең батыр тикшерүчесе белән аз кызыксынды. Скоттның үзе үлгәннән соң якын кешеләренең язмыш кочагына ташланачакларыннан куркуы бик аңлаешлы.

Бу ялгызлык хисе, җәмгыяттән, үз дәүләтеннән аерылу хисе үткән замандагы котыпчыларның барсының да юлдашы булды.

Совет кешеләренә, совет галимнәренә, совет тикшерүчеләренә андый хисләр таныш түгел. Седовчыларның данлыклы экспедициясе үзенең һәрбер адымын бөтен халыкның, хөкүмәтнең һәм иптәш Сталинның күзәтеп торуын бик яхшы белде. Шуңа күрә дә алар тырышып эшләделәр. Алар үз язмышлары, үз якыннарының һәм туганнарының язмышлары турында тыныч булдылар. Совет кешеләренең бөек бәхете әнә шунда.

„Седов“ның хәрәкәте тизләнгәч иптәш Сталин карабны бозлардан чыгару өчен экспедиция оештырырга такдим итте. Хәрәкәттәге бозваткыч пароходка каршы иң куәтле „И. Сталин“ бозваткычы җибәрелде. Ул Мурманскидан 15 нче декабрьдә чыгып, Төньякка—Гренландия диңгезенә таба, легендар „Седов“ ка каршы юл алды.

„Седов“ ның героик экипажы, Сталин исме белән, Арктика шартларында көрәш алып барды, Сталин исме белән ул үзенең тарихи хәрәкәтен җиңүле рәвештә тәгәлли. „Седов“ үзәк котып бассейны бозлары арасында торган вакытта җибәрелгән радиограммаларның берсендә куркусыз котып моряклары иптәш Сталинга болай дип яздылар:

— Сезнең исмегез, иптәш Сталин, безнең өчен, безне Ватанга җиңүчеләр итеп китерәчәк юл күрсәтүче йолдыз булып тора.

Седовчылар үз сүзләрендә нык тордылар. Алар Сталин заданиесен намус белән үтәделәр. (ТАСС).

ЙӨЗПОТЧЫЛАР ЯРЫШЫ

БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘР

Апас районының Чапаев исемендәге колхоз членнары Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының мөраҗәгатен тикшереп һәм аңар кушылып язгы чәчүгә хәзерлек эшләрен уңышлы тәгалләү буенча конкрет йөкләмәләр алганнар иде. Колхозчылар үз йөкләмәләрен зур дәрт белән үтиләр.

Язгы чәчү өчен кирәкле 1.129 центнер орлык чистартылып, коры урынга салып куелды. Авыл хуҗалыгы машиналары ремонттан чыккач акт белән кабул ителде. Ремонтта эшләүчеләрдән Галиуллин һәм Сибгатуллин иптәшләр норманы 125 процент үтәделәр.

Кышкы агротехника чараларын үткәрү, җирле ашламалар җыю эшләре дә уңышлы бара. 297 гектарда кар тотылды. Басуга 2.446 йөк тирес чыгарылды. 43 центнер көл, 62 центнер фикаль җыелды. 76 центнер компост ашлама хәзерләнде.

Колхозчылар агротехниканы зур тырышлык белән өйрәнәләр. Түгәрәккә 36 кеше йөри. Агротехник иптәш Ногманов занятиеләргә яхшы хәзерләнеп килә.

Колхоз правлениесе язгы чәчүгә хәзерлектә отлично күрсәткеч бирүчеләрне бүләкләү өчен аерым фонд билгеләде.

С. Шамбин.

БЕЗНЕҢ ЫШАНЫЧ НЫК

Аксубай районында йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылучы колхозлар, бригадалар һәм звенолар саны көннән-көн арта бара. „Үсәр" колхозы бригадалары да бу хәрәкәткә зур дәрт белән кушылдылар.

Мин „Үсәр" колхозында агротехник булып эшлим. Күп еллык тәҗрибәдә, аеруча соңгы ике елда, гектарыннан йөз пот иген уңышы алырга мөмкин икәнлегенә нык ышандым. Тик агротехника чараларын дөрес үткәрергә, туфракта дым туплап, аны сакларга һәм, ниһаять, туфракны ашлауга нык игтибар бирергә кирәк.

Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының мөраҗәгатен тикшергәннән соң без 3.000 гектар мәйданда бөртекле культураларның һәр гектарыннан йөз пот һәм 175 гектар мәйданда техника культураларының һәр гектарыннан 60 пот уңыш алырга йөкләмә алдык.

Без бу уңышны алуга ирешү өчен нәрсә эшлибез соң? Безнең быел яз сабан игеннәре чәчеләчәк җирләребез бөтенесе дә 20—22 сантиметр тирәнлектә тунга сөреп калдырылганнар. 1.000 гектар мәйданда кар тоту чаралары үткәрдек. Барлык тиресне басуга чыгарабыз. 400 тонна чамасы компост ашлама хәзерлибез, 100 центнер көл җыйдык инде. Чәчү орлыкларын җитәрлек хәзерләдек. Аларның сыйфаты яхшы.

С. Әбраров.

Аксубай районының „Үсәр" колхозы агротехнигы.

АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРҮ УҢЫШЛЫ БАРА

Әтнә районының Киров һәм Ленин исемендәге колхозлары игенчелектән мул уңыш алу буенча үткән ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнаштылар. Күргәзмә Комитеты бу колхозларны беренче дәрәҗә диплом, җиңел автомобиль һәм 10 ар мең сум акча белән бүләкләде.

Бу колхозлар быел тагын да мулырак иген уңышы алу өчен көрәшәләр. Киров исемендәге колхоз членнары йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылып, быел башаклы культураларның һәр гектарыннан 100 пот, кузаклы культураларның һәр гектарыннан 76 пот, җитенең һәр гектарыннан 25 пот уңыш алу турында йөкләмә алдылар.

Бу йөкләмәне тулысынча үтәү өчен хәзер колхозда ныклы көрәш бара. Язгы чәчү өчен кирәкле орлык җитәрлек хәзерләнде. Кышкы агротехника чараларын үткәрүгә нык әһәмият бирелә. Колхозчылар өчен системалы рәвештә агротехника укулары алып барыла.

Иптәш Гайнуллин бригадасы басуга тирес чыгару планын 150 процент, фикаль җыю планын 178 процент һәм басуга тирес чыгару планын 182 процент үтәде инде.

Ленин исемендәге колхоз членнары да кышкы агротехника чараларын уңышлы үткәрү, язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнү өчен көрәшәләр.

Егоров.

АЛДЫНГЫЛАР САФЫНДА

Кукмара районының Байлангар, „Электро", „Әзлән" һәм „Победа" колхозлары язгы чәчүгә хәзерлек буенча алдынгылар сафында баралар. Бу колхозларда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау тәгалләнде, кышкы агротехника чараларын үткәрү киң җәелдерелде.

Байлангар авылы колхозында (председателе иптәш Хәйруллин) машиналар һәм инвентарьлар яхшы сыйфатлы итеп ремонт ясаганнан соң бригадирларга акт белән тапшырылды. Барлык бригадалар да үзара ярышып эшлиләр. Колхоз хәзер басуга 900 йөк тирес чыгарды. 250 гектарда кар тоту чаралары үткәрелде. Җирле ашламалар хәзерләү планы 60 процент үтәлде.

Агротехника түгәрәкләренә 75 колхозчы тартылган. Аларның 25 е стахановчылар. Түгәрәкләргә агротехник иптәш Мифтахов җитәкчелек итә. Занятиеләр расписание буенча 5 көнгә бер тапкыр үткәрелә.

„Электро" колхозы членнары да язгы чәчүгә хәзерлекне уңышлы тәгалләп, районда мактаулы урын алу өчен көрәшәләр. Биредә 255 гектарда кар тотылды, 112 центнер көл җыелды, 33 сабанга ремонт ясалды.

„Победа", „Әзлән" колхозлары язгы чәчүгә кирәкле орлыкларны хәзерләп тиешле кондициягә җиткереп куйдылар. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау тәгаллләнү алдында тора.

Калинин районы алдынгыларының мөраҗәгатен өйрәнгәннән соң Байлангар, „Әзлән" һәм „Победа" колхозлары ефремовчы берәр звено, „Электро" колхозы 2 звено оештырдылар.

Г. Галиев.

Бакчачылык хуҗалыгындагы кимчелекләрне бетерергә

Сталинчыл бишьеллыклар чорында Татарстан АССР ның җиләк-җимеш хуҗалыгы ике өлеш үсте. 1929 нчы елда җиләк һәм җимеш бакчалары бары 6.100 гектар булса, хәзер 11 мең гектарга җитте. Элек мондый бакчаларның күпчелеге Волга буендагы 5—6 районда гына тупланган булса, хәзер алар республиканың барлык районнарында да дип әйтерлек бар.

Арча районының „Авангард", „Батыр Курса" һәм „8 нче март" колхозларында бик яхшы бакчалар оештырдылар. Ул бакчалар беренче җимешне бирә башлыйлар инде. Минзәлә, Биектау, Ширәмәт һәм Шөгер районнарында да йөзләрчә гектар мәйданда оештырылган яшь бакчалар бар. Минзәлә районының „Дружба" колхозында 16 гектар мәйданда яшь бакча һәм 30 гектар мәйданда җимеш агачлары питомнигы бар. Аның питомнигы план нигезендә ел саен 15 мең данә икешәр яшьлек алма агачлары җитештереп тора. „Дружба" колхозы җимеш бакчасыннан һәм питомниктан 1938 нче елда 24 мең сум доход алган булса, 1939 нчы елда 60 мең сум алды. 1937 нче елны колхозчыларның һәр хезмәт көненә бары 48 әр тиен генә акча тигән булса, 1939 нчы елны 2 сум бүленде.

Республикабызның җиләк-җимеш хуҗалыгына Мичурин җитештергән иң кыйммәтле сорт җимеш агачлары елдан-ел киңрәк күләмдә кертелә. Мәсәлән, тик соңгы ике ел эчендә генә дә Мичурин сортларыннан 55 мең төп агач утыртылды.

Безнең Татарстан АССР да җиләк-җимеш хуҗалыгын үстерү өчен гаять зур мөмкинлекләр бар. Җир Эшләре Халык Комиссариаты карамагында 7 питомник һәм тагын 23 колхозда питомниклар бар. Тик соңгы ике ел эчендә генә дә бу питомниклар ике яшьле 370 мең данә алма агачы, 500 мең данә җиләк агачлары җитештерделәр.

Минзәлә районының „Дружба", Ширәмәт районының „Красноармеец", Шөгер районының „Шушма", Әлмәт районының „Зәй" һәм Кама Тамагы районнарының „Октябрь" колхозлары питомниклары һәрберсе ел саен берничә районны җиләк-җимеш агачлары белән тәэмин итеп киләләр. Аларның җитештерә торган җиләк-җимеш агачларының 20 проценты Мичурин сортлары.

Соңгы елларда колхозчылар арасыннан атаклы бакчачылар үсеп чыктылар. Безнең бакчачыларыбыздан Сәлимҗанов (Шөгер районы), Шакиров (Әлмәт районы), Исаев (Ширәмәт районы) һәм Костин (Минзәлә районы) иптәшләрне Татарстан АССР да гына түгел, союзның күп кенә башка өлкә һәм республикаларында да беләләр. Алар бакчачылыкны фән нигезендә алып баралар. Тәмтедәге җиләк-җимеш тәҗрибә станциясе һәм Мичурин институты белән даими элемтә тоталар.

Җиләк-җимеш бакчаларында агротехника чараларын дөрес үткәрү нәтиҗәсендә, үз бакчаларыннан яхшы уңыш алуга ирешкән колхозлар бездә бар. Мәсәлән, Тәмте районының Тукай исемендәге колхозы соңгы ике елда алма бакчасының һәр гектарыннан уртача 40 центнер уңыш алды. Тәмте районының Калинин исемендәге колхозы 86 гектар мәйданда алманың һәр гектарыннан 55 центнер уңыш алды.

Бакчачылык эшендә әнә шундый зур уңышларга ирешкән колхозлар белән бер рәттән, бездә бу эшкә җитәрлек әһәмият бирмәүче колхозлар да бар әле. Электән бакчачылык белән шөгылләнеп килгән Темте, Югары Ослан һәм Кама Тамагы районнарының кайбер колхозларында җимеш-җиләк бакчалары ташландык хәлдәләр. Агрономия чаралары яисә бөтенләй үткәрелми, яисә бик аз күләмдә үткәрелә. Мәсәлән, Тәмте районының Каганович исемендәге колхозында 70 гектар мәйданда җимеш бирүче бакчасы һәм 6 гектар мәйданда яшь бакчасы бар. 1939 нчы елны бу бакчаның бары 22 гектар мәйданында гына агач төпләре йомшартылды һәм бары 10 гектарында гына алма корткычларына каршы көрәш чаралары үткәрелде. Ашлама исә бу бакчага тоташтан берничә ел инде бөтенләй кертелгәне юк. Шул ук районның Буденный исемендәге колхозында да алма бакчасының бары 40 процентында агрономия чаралары үткәрелде. Нәтиҗәдә, бу колхозда алма бакчасының һәр гектарыннан бары 15 центнер уңыш чыкты. Кама Тамагының „Коминтерн" һәм „Совместный Труд" колхозларында да шундый ук хәл.

Кайбер колхозларда бакчачылык бригадаларын ныгытуга игтибар бирелми. Тәмте районының Ворошилов исемендәге колхозында 70 гектарлык бакчага бары 7 кешелек бригада төзегәннәр. Шул ук районның Мичурин исемендәге колхозында 38 кешедән бригада төзегән булганнар. Шул 38 кешенең 22 се быел бакча эшендә бөтенләй катнашмаган. Кайбер колхозларда бакчаларның коймалары юк. Аларга терлекләр кереп йөриләр, 1939 нчы елны гына да Тәмте районында 5 мең төп алма агачы шул сәбәпләр аркасында корыды. Шунсы гаҗәп: әнә шул кимчелекләргә юл куючылардан бер генә кеше дә җавапка тартылмады.

Якындагы елларда һәрбер колхозда җәмагатьләштерелгән җимеш бакчасы, һәрбер колхозчының һәм авылда торучы һәрбер хезмәткәрнең кимендә 15—20 данә алма агачлы алма бакчасы һәм чия бакчасы булырга тиеш. Без җиләк-җимеш хуҗалыгын әнә шуңар тулысынча җавап бирерлек итеп оештырырга тиешбез.

Җиләк-җимеш хуҗалыгыннан алына торган продукциянең колхозларны ныгытуда һәм колхозчыларның, гомумән барлык хезмәт ияләренең тормышларын яхшыртуда гаять зур урын тотуын истән чыгарырга ярамый. Җиләк-җимеш хуҗалыгындагы кимчелекләрне бетерергә һәм авыл хуҗалыгының бу тармагын да үрнәк булырлык итеп оештырырга кирәк.

Хәсәнев.

Татнаркомземның яшелчә управлениесе начальнигы.

Казан, киез итек-фетр фабрикасының түшәү цехында просмотрщица булып эшләүче стахановчы София Габидуллина. Ул эшләп чыгаруның еллык планын август аенда тәгалләде. И. Галиев фотосы.

АЗЫК ПРОМЫШЛЕННОСТЫ 1940 НЧЫ ЕЛДА

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды безнең алга хезмәт җитештерүчәнлеген алда да барлык чаралар белән күтәрү, бай техниканы тагын да яхшырак үзләштерү бурычын куйды.

Татарстан АССР ның азык промышленносты предприятиеләре бу мактаулы һәм җаваплы бурычларны үтәү өчен большевикларча көрәшкән хәлдә, әледән-әле яңа уңышларга ирешәләр. 1939 нчы ел йомгаклары бездә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен эчке мөмкинлекләрнең гаять зур булганлыгын ачык күрсәтте. 1940 нчы ел планын билгеләгәндә, без әнә шул гаять зур мөмкинлекләрдән чыгып эш иттек.

„Кызыл Шәрык" сыра заводы буенча быел 250 мең гектолитр (узган елны 220 мең гектолитр иде) сыра кайнату һәм 90 мен гектолитр фрукт сулары (узган елны 85 мең гектолитр иде) эшләп чыгару билгеләнде. Болардан тыш, „Кызыл Шәрык" заводы 1940 нчы елда 20 мең гектолитр брага һәм алкогольсез коры эчемлекләр эшләп чыгарачак.

Бу планны үтәү өчен заводның мөмкинлекләре зур. Завод коллективы 1939 нчы ел уңышлары белән мавыкмаска, эчке мөмкинлекләрне файдалану өчен барлык чараларны күрергә тиеш. Заводны реконструкцияләү эшенә билгеләнгән 1 миллион сум акчаны рациональ рәвештә файдалану, югалтуларга каршы аяусыз көрәш, чималга экономия ясау, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен технологик эш процесларын яхшырту— коллектив алдында торган мактаулы бурычлар әнә шундый.

Микоян исемендәге кондитер фабрикасы алдында да гаять зур бурычлар тора. Фабрика быел 4.675 тонна кондитер эшләп чыгарырга тиеш, моның өчен чималны планга караганда артык тотуны бетерергә, хезмәтне оештыру эшен яхшырту белән хезмәт җитештерүчәнлеген кискен рәвештә югары күтәрергә, 1939 нчы елдагы кебек артта калучылыкны бетерергә кирәк.

Макарон фабрикасы 1940 нчы елда 5.000 тонна макарон эшләп чыгарачак. Фабрика коллективы быел киптерү хуҗалыгын яхшыртырга, онны артык тотуны һәм аппаратураның эшсез торуларын бетерүгә, тара һәм ярдәмче материаллар бәясен киметергә, продукциянең сыйфатын яхшыртырга тиеш.

Сага заводлары буенча 1.450 тонна сага, **Мальтоз заводы** буенча 1.600 тонна мальтоз һәм 300 тонна патки эшләп чыгару билгеләнде. **Уксус заводы** быел 3.600 гектолитр уксус бирергә тиеш. Монда ак уксус эшләп чыгару белән бергә, башка төрле уксус эшләүне үзләштерү бурычы да куела. Продуктларның сыйфатын яхшырту һәм төрләрен күтәрү бурычы азык промышленносты предприятиеләре алдында торган мактаулы бурычларның берсе.

Районнарда азык промышленносты предприятиеләрен киңәйтү, киң куллану товарлары эшләп чыгаруны үстерү, продуктларның муллылыгы өчен көрәш өлкәсендә зур чаралар үткәрелә. Быел Дөбъяз, Кукмара, Актаныш, Мамадыш, Яңа Писмән, Ютазы, Кама Тамагы, Минзәлә, Алабуга, Чаллы, Тәтеш, Буденный, Баулы, Шөгер, Кызыл Юл районнарында азык промышленносты предприятиеләрен оештырабыз. Узган елны Әлмәт, Красный Бор, Буа, Тәкәнеш, Мөслим, Питрәч һәм башка районнарда оештырылган мондый предприятиеләр үзләрен тулаем акладылар. Азык предприятиеләре өчен урыннарда мөмкинлекләр гаять зур. Алар чимал белән дә тулысынча тәэмин ителгәннәр. Шул ук вакытта ул предприятиеләр транспорт эшен дә җиңеләйтәләр, транспортны шәһәрләрдән районнарга, продукт ташу кебек өстәмә эштән коткаралар. Шуңа күрә дә азык промышленносты предприятиеләрен республикабызның барлык районнарында да булдыру мәсьәләсенә игтибарны ныграк тупларга кирәк. Чөнки икмәк пешерү, төрле сортлы прянникләр, печеньеләр, токмач, макарон җитештерү эшен һәрбер районда оештырырга мөмкин.

Районнарда оештырыла торган предприятиеләрнең куәте айга 3 тонна прянник, бер тонна икмәк-булки, 1,5 тонна конфект, 500—1.000 гектолитр алкогольсез эчемлекләр җитештерү күләмендә билгеләнә.

Алда торган бу бурычларны үтәү тирәсенә без, азык промышленносты работниклары, барлык игтибарны туплarбыз һәм бу бурычларны тулысынча үтәү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

П. Сечин.

ТАССР азык промышленносты наркомының урынбасары.

СОВЕТ БАЛАЛАРЫ БӘЙРӘМЕ

Советлар Союзының һәр почмагында балалар театрларына смотр бара. Күп урыннарда бу смотр совет балаларының зур бәйрәме булып әверелде. Театрлар үзләренең яхшы постановкаларын куеп, җәмагатчелек алдында, үзләренең яшь тамашачылары алдында отчет ясадылар, алар тамашачыларның махсус конференцияләрен, үзләренең иң яхшы мастерларының иҗади кичәләрен үткәрделәр, комсомол һәм пионер работниклары белән, ата-аналар һәм педагоглар белән очрашып, театрларның эшләре турында фикер алыштылар. Спектакльләрне тикшерүдә сәнгатьнең зур мастерлары катнаштылар.

Ил чигенең теге ягында, капиталистик илләрдә мондый смотрларны үткәрү һич тә мөмкин түгел, чөнки анда балалар театрлары бөтенләй юк. Андый театрларны патша Россиясе дә белмәде. Бары тик Советлар Союзында гына балалар өчен махсус театрлар төзеләләр. Бездә балалар партия, хөкүмәт һәм бөтен халык тарафыннан зур кайгыртучанлык күрсәтү белән чолганып алынганнар. Балалар алдында сәнгатьнең иң яхшы мастерлары чыгыш ясыйлар.

Совет власты балалар театрларына куәтле материаль база бирде. 1939 нчы елда бу театрларның эшләренә хөкүмәт 35 миллион сум акча билгеләде. Яшь тамашачылар театрларына яңа, гүзәл биналар салу өчен зур сумалар җибәрелә. Соңгы ике ел эчендә Киевтә, Саратовта, Новосибирскидә, Ростов-Донда балалар өчен яңа театрлар эшли башладылар.

Балаларның беренче театры 1918 нче елның 7 нче ноябрендә ачылган иде. Интервенциягә каршы, эчке дошманнарга каршы каты көрәш барган вакытта да, җимереклек һәм ачлык елларында да яшь совет республикасы яшь гражданнарның театрлары турында онытмады. 1920 нче елда Харьковта әкият театры ачылды, 1921 нче елда Ленинградның яшь тамашачылар театры эшли башлады. 1935 нче елда балалар театрларының саны 35 кенә иде әле, ә хәзер алар 149 га җиттеләр. Шулардан 68 театр—милли республикаларда. Сталинчыл өченче бишьеллыкның ахрына балалар театрларының саны 2 тапкыр артырга тиеш.

Балалар театрлары пьесаларны СССР халыкларының телләреннән 18 телдә: әрмән, үзбәк, таҗик, грузин, еврей, белорус һәм башка телләрдә куялар. Территориясендә революциягә кадәр театр предприятиеләре булмаган бер Үзбәкстанда гына да хәзерге көндә яшь тамашачыларның 8 театры бар.

Безнең иң яхшы яшь тамашачыларыбызның көче шунда ки, алар үзләре алдында торган бурычның әһәмиятен тулысынча аңлап иҗад итәләр, үзләренең яшь тамашачыларына сөю һәм ихтирам белән карыйлар. Бу театрларда күренекле актерлардан һәм режиссерлардан халык артисты А. Брянцев, атказанган артист Б. Зон, сәнгатьнең атказанган эшлеклеләре Л. Макарьев, И. Аркадин, Н. Маршак (Грузия), атказанган артистлар Б. Блинов, Е. Уварова, А. Охитина, М. Шифман, А. Такаишвили (Грузия), Б. Мирович (БССР) һәм күп кенә башкалар эшлиләр.

Культураның бөек мастерлары (Ломоносов, Гутейберг, Галилей һ. б.) турындагы, революциянең геройлары турындагы пьесалар, әкиятләр, классик драматургларның әсәрләре балалар өчен булган репертуарда күренекле урын алып торалар.

Балалар театрларының сәхнәләрендә Островскийның—16, Горькийның—8, Мольерның—6, Гальдониның—7 пьесасы, Пушкин, Лермонтов һәм Руставели әсәрләре куела. Быелгы репертуарга кертелгән пьесаларның яртысы граждаңнар сугышын, хәзерге заман тормышын, совет мәктәбен чагылдыралар.

Совет язучыларыннан, шагыйрьләрдән һәм драматурглардан 200 дән артык кеше балалар театрлары өчен эшлиләр.

1935 нче елда милли драматургларның бары тик 12 пьесасы яшь тамашачылар театрларының репертуарларына кертелгән иде, 1939 нчы елда бу пьесалар саны 52 гә җитте. Аларның күпләре тугандаш халыкларның телләренә күчереләләр һәм күп кенә республика театрларында куелалар.

Курчак театрларының репертуарында әкиятләр төп урынны алып торалар. Соңгы вакытларда күп кенә совет әкиятләре барлыкка килделәр. Аларда безнең хәзерге чынбарлыгыбыз күрсәтелә.

Балалар театрлары спектакльләр күрсәтү белән бергә, тамашачылар арасында гаять зур эш алып баралар, алар күргәзмәләр, диспутлар, яңа пьесаларны мәктәпләрдә укулар, спектакльләр буенча фикер алышулар, иң яхшы актерларның тамашачылар белән очрашуларын һәм башкаларны оештыралар.

Бөтенсоюз смотрының жюрие иң яхшы 10 театрны сайлап алу эшен шушы көннәрдә тәмам итәчәк. СССР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Комитеты шушы театрларның күргәзмә постановкаларын 1940 нчы елның февраль аенда Москвада куячак.

Урыннарда булып үткән смотр театрлар коллективының көчен, талантын ачык күрсәтте. Ләкин, шуның белән бергә, смотр балалар театрларының эшләрендә булган зур кимчелекләрне дә ачты. Кайбер пьесаларның сыйфатлары түбән. Балаларны семьядә, мәктәптә тәрбияләү турындагы, дуслык турындагы, коллектив турындагы темаларга язылган яхшы пьесаларның җитәрлек булмавы аеруча күзгә чагылды.

Смотр вактында җыналган барлык иҗади уйлар һәм такдимнәр балалар театрлары работникларының беренче Бөтенсоюз иҗади конференциясендә бергә тупланачак.

О. Олидор.

УКЫТУЧЫ-АКТИВИСТ

Варвара Филипповна Васильева Кызыл Йолдыз урта мәктәбендә химия-биология фәненнән VII, VIII, IX һәм X нчы классларда укыта. Ул җәмагать эшенә дә актив катнаша, комсомол комитетының секретаре булып эшли. Иптәш Васильева күп кенә укучы яшьләрне комсомолга керергә хәзерләде. 1937 нче ел башында мәктәптә бары 22 комсомолец булса, хәзер 92 комсомолец бар. Укучы яшьләрдән 42 кеше ГСО значкистлары итеп хәзерләнде.

Иптәш Васильева сайлаулар вактында агитатор булып эшләде. Сайлауларга хәзерлек чорында сайлаучылар өчен „Җирдә тереклекнең килеп чыгуы" дигән темада 8 урында лекция укыды. Йорт хозяйкалары арасында агитация-масса эшен өзлексез алып бара.

Иптәш Васильева „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"ның VII бүлеген конспект төзеп өйрәнде. Ул парткабинетка актив йөри, групповой һәм индивидуаль консультацияләргә якыннан торып катнаша, партия оешмасы иптәш Васильеваны шушы көннәрдә ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алды.

Сәйфеттинев.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенчә, көнбатыш фронтта артиллериядән атышуның җанлануы разведка эшләренең көчәюе белән аңлатыла. „Фронтның төрле секторларында безнең разведка оборонаның алгы полосасында соңгы вакытка кадәр французлар кулында булган кайбер районнарның французлар тарафыннан инде калдырылганлыгын белде. Германия разведкасының аннан соңгы хәрәкәтләре белән дошманның алдынгы постларының кайда икәнлеге ачык маглүм булды. Сугыш операцияләре булмады. Англия һәм Шотландия ярларына Германия самолетларының налеты вактында дошманның барлыгы 15.000 тоннадан артык авырлыктагы берничә судносы юкка чыгарылды“.

Германиянең иң яңа конструкциядәге 4 самолеты бүген Германия бухтасы турысында булган һава сугышында Англиянең „Бристоль—Бленхейм“ типындагы бомбардировщиклар эскадрилиясе (9 самолет) белән очраштылар. Англия бомбардировщиклары Германия самолетларының якынлашуы белән үк көнбатышка таба борылдылар һәм качарга маташтылар. Англиянең өч бомбардировщигы бәреп төшерелде. Германиянең барлык самолетлары үз базаларына кайттылар.

ПАРИЖ, 10 гыйнвар. (ТАСС). Кичә фронтта Франция патрульләренең шактый зур активлыгы булуы турында хәбәр ителә. Төн тыныч үткән. Вогезыдан көнчыгышка таба булган районда алгы частьләрнең җирле характердагы активлыгы күренгән.

БЕРЛИН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе: „Көнбатыш фронтының кайбер участкыларында җирле характерда шактый җанлы төстә артиллерия хәрәкәте күренде“ дип хәбәр итә.

Германия информация бюросы,—көнбатышта сугыш хәрәкәтләре зонасында көчле салкыннар аркасында Франция командованиесе колония гаскәрләренең зур өлешен көньякка күчерде, дип хәбәр итә. Көньяк Франциядә тупланган шундый гаскәрләрнең саны 250—300 мең кешедән гыйбарәт.

ЛОНДОН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия самолетлары узган төнне Германиянең төньяк-көнбатыш өлешендә разведка очышы үткәргәннәр.

ЛОНДОН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгы, 22 яштән 23 яшькә кадәр булган һәм узган елның декабрь башында регистрация үткән военнообязанныйларның беренче контингентын бүген армиягә чакыру башланганлыкны хәбәр итә. Военнообязанныйларның бу группасында 240 мең кеше санала.

ЛОНДОН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Франциядә Англиянең коралды көчләре артканлыктан маршал Барратны Англиянең Франциядәге һава көчләренең баш командующие итеп билгеләү турында карар кабул ителде. Ул, Франция командованиесе белән берлектә, көнбатыш фронтта Англиянең һәм Франциянең һава көчләренең операцияләренә юнәлеш биреп торачак.

ЛОНДОН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Кичә Англиянең 10.000 тонна авырлыктагы һәм Көньяк Африкага бара торган „Дунбар Касл“ исемле пассажирлар пароходы минага бәрелеп баткан. Анда булган 200 кешенең күпчелеге коткарылган.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, 8.485 тонна авырлыгындагы „Британиш Либерти“ танкеры Төньяк диңгездә минага бәрелгән. Командадан 20 кеше һәлак булган.

БЕРЛИН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Англиянең сәүдә флоты гыйнварның беренче атнасында барлыгы 36.133 тонна авырлыктагы берничә пароходын югалткан.

ЛОНДОН, 10 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, гыйнварның беренче яртысында Англия контроле Германия өчен билгеләнгән 6.200 тонна йөкне тотып алган. Сугыш башланганнан бирле тотылган йөкләрнең бөтен күләме 544.000 тоннага җитә.

МЕКСИКАДАГЫ ХӘЛЛӘР

НЬЮ-ЙОРК, 9 гыйнвар. (ТАСС). Мексика газетасы „Эль популер“, Мексиканың төрле районнарында реакцион генерал Альмасан тарафдарларыннан хөкүмәткә каршы чыгучылар саны күбәйде, дип яза. Бу, дип күрсәтә газета, реакционерларның президентка булачак сайлауларда үзләренең җиңелүләреннән куркып, яңа коралы баш күтәрү хәзерләүләрен раслый.

Австралиягә Американың илчесен билгеләү

ВАШИНГТОН, 9 гыйнвар. (ТАСС). Рузвельт Американың Кытайдагы илчесенең советнигы Гауссны АКШ ның Австралиядәге илчесе итеп билгеләде.

Англия хөкүмәте ирландлыларга ватаннарына кайтуны тыя

БЕРЛИН, 9 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Англия хөкүмәте 21 дән 28 яшькә кадәр булган һәм Эйрегә кайтырга теләкләрен белдергән 40 мең ирландлыларга Англиядән китү өчен виза бирүдән баш тарткан. Баш тартуга нигез итеп, Англиядә ике елдан артык яшәүче кешеләр хәрби обязанныйлар булып хисапланалар дигән сылтау күрсәтелә. Эйренең баш министре де Валера шушы уңай белән Англия хөкүмәтенә протест белдергән.

Англия профбюрократлары эш өстендә. В. Лисевич рәсме (ТАСС фото-клишесе).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шанхай газеталарының язуына караганда, Кантоннан төньяктарак кытай гаскәрләре өч колонна булып көньякка таба баралар. 8 нче гыйнварда кытай гаскәрләренең үзәк колоннасы Цунхуадан көнбатыштарак, Кантон—Ханькоу тимер юлында Юньтань дигән әһәмиятле бер пунктны алган. Шул ук көнне уң фланг часте Юньтаньнан көнбатыштарак Цинюаньны алган. Сул фланг колоннасы Цзэнчэнгә таба уңышлы рәвештә алга бара. Япон гаскәрләре зур югалтулар белән чигенәләр.

Гуандун провинциясенең көнчыгыш өлешендә Кытай гаскәрләре Чаочжоуның төньяк-көнчыгыш бистәләрендә берничә пунктны алганнар. Бу районда сугышлар берничә көннән бирле бара инде.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин—Циньчжоу юлындагы районда хәрәкәт итүче кытай частьләре соңгы көннәрдә берничә пунктны алганнар һәм 9 нчы гыйнварда Наньнинга җитәргә 15 километрда гына калганнар.

8 һәм 9 нчы гыйнварда Наньниннан төньяк-көнчыгыштарак кытай һәм япон гаскәрләре арасында бик каты сугышлар булган. Кытайлар Наньниннан төньяк-көнчыгышта 35 километр ераклыкта Цзяотанны алганнар. „Синьвэньбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, японнар бу районда меңләп солдатларын югалтканнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Хунань—Хубэй чигендә кытай гаскәрләре Янлоутун һәм Шуаньканьkоу пунктларын японнардан чистартканнар.

Хэнань провинциясенең көньяк өлешендә, Синьяннан төньяк-көнбатыштарак кытай гаскәрләре, самолетлар белән берлектә һөҗүм итеп килүче 1.300 кешелек япон отрядының атакасын кире каккannar. Сугышта инициативаны кытайлар үз кулларында тоталар.

МАНЧЖУРИЯДӘ КАРТОЧКА СИСТЕМАСЫ

ТОКИО, 10 гыйнвар. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы, Манчжурия хөкүмәтенең февраль уртасыннан башлап дөгегә һәм башка азык товарларына карточка системасы кертергә карар бирүен хәбәр итә.



Советлар Союзы шәһәрләре буенча. РӘСЕМДӘ: Белосток шәһәрендә плюш эшләү фабрикасы. (Самолеттан төшереп алынган рәсем).

Д. Чернов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА

КОЛХОЗ БАЗАРЛАРЫН ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

Илдә яңа базарлар, өсте ябулы павильоннар, чәйханәләр, ашханәләр, сөт һәм ит контроле станцияләре төзелешенә, колхоз базарларына асфальт һәм таш җәюгә узган ел 60 миллион сумга якын акча тотылды. 1940 нчы елны колхоз базарларын төзекләндерүгә 100 миллион сумга якын акча билгеләнә.

КОЛХОЗЛАРДА СТАХАНОВЧЫЛАР МӘКТӘПЛӘРЕ

Калинин өлкәсе колхозларында кыр стахановчылары өчен 1.000 мәктәп һәм терлекчелек стахановчылары өчен 700 мәктәп оештырылды. Бу мәктәпләрдә Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашучыларның алдынгы тәҗрибәсен 27 меңнән артык звеночы, бригадир һәм терлекчелек фермалары работниклары өйрәнәләр. Лекцияләр уку эшенә белгечләр, шулай ук стахановчы колхозчылар чакырылды.

КЫРЫМДА КӨЧЛЕ САЛКЫННАР

Кырымда көчле салкыннар башланды. 10 нчы гыйнварда Симферопольдә һаваның температурасы нульдән түбән 20 градус булды. Район үзәге Сейтлердә салкынлык 30 градус. Ай—Петри районында күп кенә кар яуды. Салкыннар 24 градуска җитә. Салкын һавага карамастан, диңгездә суның температурасы 8 градус җылы.

МОПРНЫҢ ҖИТӘКЧЕ ОРГАННАРЫНА ОТЧЕТ - САЙЛАУ КАМПАНИЯСЕН ОЕШКАН РӘВЕШТӘ ҮТКӘРИК

10 нчы гыйнвардан МОПР ның җитәкче органнарында отчет-сайлау кампаниясе башланды. Республикабыздагы МОПР оешмалары бу кампанияне интернационал тәрбия һәм оештыру эшләрен яхшырту белән каршылыйлар. Мәсәлән, 1939 нчы ел эчендә ресбупликабыздагы МОПР оешмаларында сигез меңнән артык лекция укылды. Казан шәһәрендәге МОПР оешмалары революцион көрәшчеләргә: Тельман, Ракоши, Антикайнен, Метенброцкий һәм башкаларга, шулай ук Париж коммунасына 68 ел тулуга багышлап, 47 тапкыр интернационал кичә оештырдылар. Республикада 305 урында МОПР почмагы һәм 83 урында чит илләрдәге вакыйгаләр почмагы оештырылган. Капиталистик илләрдәге политик тоткыннар белән интернационал элемтә эшләре дә яхшыра бара. 1939 нчы елда төрле илләрдәге политик тоткыннарга 57 хат язылган. Татарстандагы МОПР оешмалары 1939 нчы елның 11 ае эчендә СССР МОПР Үзәк Комитетының счетына 322 мең сум акча күчергәннәр. 1938 нче елның ноябрь аенда МОПР ның җитәкче органнарына булып үткән сайлаулардан соң МОПР членнарының саны 26.719 кешегә арткан. Хәзер республикабызда МОПР комитетларының һәм ячейкаларының саны 2.438 гә җитә һәм аларда 114.743 кеше учетта тора.

МОПР ның Ворошилов, Тымытык, Кузнечиха, Сталин, Бауман район оешмалары аеруча яхшы эшлиләр. Мәсәлән, узган елны Бауман районындагы МОПР оешмаларында 1.184 тапкыр лекция тыңланган һәм беседалар, 12 тапкыр интернационал кичә үткәрелгән, 35 урында МОПР почмаклары оештырылган. Масса-аңлату эшләре тиешле югарылыкка куелу нәтиҗәсендә, МОПР сафларына 3.559 кеше кабул ителгән.

Вахитов исемендәге завод һәм Казпогрузтрестның икенче гражданский фабрикасы (Казан шәһәре) янындагы МОПР комитетлары интернационал тәрбия эшләрен производство эшләре белән бергә бәйләп алып баралар. Бу предприятиеләрдә революцион көрәшчеләр исеменә оештырылган производство бригадалары эшләп чыгару планнарын 130—150 процент үтәп киләләр. Регуляр рәвештә МОПР стена газеталары чыгарыла, интернационал кичәләр оештырыла. Капиталистик илләрдәге политик тоткыннарга хатлар язалар. Казан Дәүләт университеты, тимер юл идарәсе һ. б. күп кенә учреждениеләр, предприятиеләр янындагы МОПР оешмалары да яхшы гына эшләп киләләр.

Шуның белән бергә, безнең республикабызда үзләренең эшләрен тиешле югарылыкка куя алмаган оешмалар да аз түгел әле. Мәсәлән, МОПР ның Яңа Чишмә, Арча һәм башка кайбер район оешмалары (секретарьлары Котов һәм Мөхәммәтҗанов иптәшләр) ел буена бер генә тапкыр да президиум утырышы һәм МОПР активистларының җыелышларын үткәрмәгәннәр. Интернационал тәрбия эшләре алып барылмый.

МОПР оешмаларының җитәкче органнарына булачак отчет-сайлау кампаниясе оешкан рәвештә, тиешле политик югарылыкта, көчле тәнкыйть һәм үз-үзеңне тәнкыйтьләү астында үтәргә тиеш. Отчет-сайлау җыелышларына барлык членнарның катнашы тәэмин ителергә тиеш. Моның өчен җыелышларның һәм конференцияләрнең кайда, кайсы көнне һәм ничә сәгаттә буласы, аларның көн тәртипләре МОПР ның һәрбер членына алдан җиткерелгән булырга тиеш.

Партия, комсомол һәм профсоюз оешмалары МОПР ның җитәкче органнарында отчет-сайлау кампаниясенә якыннан торып җитәкчелек итәргә, интернационал тәрбия эшләрен яхшырту, революцион көрәшчеләргә материаль ярдәм күрсәтү буенча МОПР оешмаларына зур булышлык күрсәтергә тиешләр.

МОПР ның җитәкче органнарына иң яхшы кешеләр, интернационал эш алып бару энтузиастлары, хезмәт үяләрен пролетар интернационализм һәм совет патриотизмы рухында тәрбияли алырлык кешеләр сайланырга тиеш.

Малков.

МОПР ның Өлкә Комитеты председателе.

Сталин районы 80 нче номерлы урта мәктәпнең пионерлары каникул вактында Г. Тукай исемендәге балалар библиотикасында уку залында.

И. Галиев фотосы.

ТЕАТРДА 181 МЕҢ ТАМАШАЧЫ БУЛДЫ

Казан Зур Драма театры 1939 нчы елда үткәргән эшләренә йомгак ясады. 8 ай вакыт эчендә Москва һәм Ленинградтагы гастроль спектакльләреннән тыш, барлыгы 226 спектакль бирелгән. Шушы вакыт эчендә театрда 181 мең тамашачы булган.

Театр коллективы үткән елгы сезонда 8 яңа постановка биргән. Аеруча зур уңыш белән „Павел Греков“, „Васса Железнова“, „Ревизор“, „Бакчалар чәчәк ата“ пьесалары барган.

1939 нчы ел театр тормышында яңа артистлар кадры үсү белән характерлы. Яшь актерлар өчен, декабрь аенда яшьләрнең иҗад көчләренә үткәрелгән смотр, җидди имтихан булып торды. Студиянең элекке укучылары смотр вактында „Ревизор“ һәм „Павел Греков“ кебек пьесаларда зур һәм җаваплы рольләрне башкардылар. Яшь артистлар үзләрен аеруча „Бакчалар чәчәк ата“ пьесасында күрсәттеләр.

Быел театр күп кенә яңа пьесалар күрсәтәчәк. Алар арасында Лермонтовның „Маскарад“ һәм Каплер, Златогорскийларның „Ленин“ пьесалары аеруча зур постановкалардан санала. Театр коллективы „Ленин“ пьесасын февральнең азагында күрсәтергә уйлый.

Орденлы шагыйр Н. И. Шелепи Аксубай районында

Чувашстанның халык шагыйре орденлы Николай Иванович Шелепи-Педерусов үзенең туган авылы Аксубай районы Беловкага кайтты. Ул районның күп кенә колхозларында һәм шулай ук Тельман, Октябрь районнарында булды.

Аксубай районында шагыйр, колхозчылар һәм интеллигенция белән очрашты. 420 кеше катнашкан җыелышта ВКП(б) райкомының работнигы иптәш Галкин Н. И. Шелепинең әдәби эшчәнлеге турында доклад ясады. Очрашуда шагыйр үзенең „Кунакта“, „Сталинчыл сайлаулар“, „Цивилья базары“ дигән шигырьләрен укыды. Педагогия училищесенең студентлары Н. И. Шелепиның күп кенә әсәрләрен башкардылар.

БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) Шәһәр Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге: Матвей Васильевич **Долгов**, Федор Алексеевич **Ерагин**, Петр Никонорович **Баранов**, Сергей Петрович **Бурматин**, Андрей Семенович **Косинкин**, Алексей Павлович **Козлов**, Антонина Ефимовна **Маркина**, Федор Антонович **Марин**, Николай Александрович **Кошин**, Павел Михайлович **Дергач**, Гликерия Андреевна **Орлова**, Николай Яковлевич **Сергеев**, Мария Степановна **Мартынова**, Иван Дмитреевич **Поляков**, Зөһрә Нигмәтулла кызы **Касыймова**, Василий Александрович **Михайлов**, Ефим Гаврилович **Мимяев**, Константин Архипович **Янышин**, Владимир Георгиевич **Серебрянников**, Петр Дмитриевич **Кукушкин** һәм Шәми Җамали улы **Җамалиев** иптәшләрнең эш сәгатьләрендә 19 нчы бүлмәгә килүләрен сорый.

Җаваплы редактор

һ. АБДРАХМАНОВ.

Ответ. редактор **Х. АБДРАХМАНОВ.**

КАЗАН АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ИНСТИТУТЫ

производстводан аермыйча укытып институтка

хәзерлек курсларына укучылар ала

Хәзерлек курсларына тәгәлләнгән урта белемле (техникум, рабфак, 10 еллык мәктәп тәгәлләгән) кешеләр алыналар.

Гаризалар шушы ел 7 нче февральгә кадәр алына. Укулар 7 нче февральдән башлана.

Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, урта мәктәпне тәгәлләү турында документ, сәламәтлеге турында медицина белешмәсе һәм 2 фотокарточка бирелергә тиеш. Казан, Карл Маркс урамы 65, Авыл Хуҗалыгы институты. 55—1

С. М. КИРОВ ИСМЕНДӘГЕ

КАЗАН ХИМИКО-ТЕХНОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ

институтка хәзерлек буенча 6 айлык курсларга өстәмә рәвештә

УКУЧЫЛАР АЛА

Курсларга тәгәлләнгән урта белемле (10 еллык мәктәп, техникум, рабфак тәгәлләгән) кешеләр алыналар.

Хәзерлек курсларында укулар производстводан аерылмыйча алып барыла.

Гаризалар, ВУЗ ларга керү өчен сорала торган документлар белән, **шушы ел 22 нче гыйнварга кадәр,** институтның кадрлар бүлегендә һәр көн иртән 9 сәгаттән кич 9 га кадәр **алына.** Казан, Карл Маркс урамы, 68. Телефон 14—98. 37—3—1

АУЧЫЛАР ҺӘМ СПОРТСМЕННАР

15 нче гыйнвар кич 6 сәгаттә, Бауман урамындагы 76 нчы йортта физкультура һәм спорт эшләре буенча Шәһәр Комитеты тарафыннан

аучылар һәм балыкчылар конференциясе үткәрелә

Көн тәртибе:

1. Секциянең 1939 нчы елгы эше турында отчет.
2. 1940 нчы елда аучыларга свидетельство бирү тәртибе турында.
3. Секциягә членнар сайлау.
4. Төрлеләр.

Физкультура һәм спорт эшләре буенча Шәһәр Комитеты. 59—1

Район кино-установкалары өчен киномеханиклар хәзерләү

буенча 7 айлык курсларга 1940 нчы ел 5 нче гыйнвардан

укучылар алына

Курсларга 17 дән түбән булмаган яштәге һәм кимендә 7 класс күләмендә белемле кешеләр алыналар.

Курсларга керергә теләгән кешеләр кинофикация трестының район бүлегенә килергә тиешләр. Казан, Бауман урамы, 60. Таткинотрест. 2625—2—2

ВАХИТОВ ИСМЕНДӘГЕ ЖИРКОМБИНАТНЫҢ

ФЗУ МӘКТӘБЕ

мәктәпнең хәзерлек группасына (руслар группасы)

УКУЧЫЛАР АЛА

Хәзерлек группасына 7 класс күләменнән түбән белемле һәм 16 дан түбән булмаган яштәге үсмерләр алыналар.

Гариза белән бергә, керүченең яше турында документ, мәктәптән, ата-анасының эшләгән урыннарыннан бирелгән һәм чәчәк салынган булу турында белешмәләр бирелергә тиеш.

Укулар 1940 нчы ел, 15 нче гыйнвардан башлана.

Тулай торак булмый. Вак-төяк расходлар өчен кечкенә стипендия бирелә. Казан, Тукай урамы, 113. Жиркомбинат техникумы бинасы (3 нче маршрут трамваеның Вахитов исмендәге завод янындагы тукталы). 2680—3—3

Казан Дәүләт Мединституты студентларын урнаштыру өчен ашыгыч рәвештә

БҮЛМӘЛӘР һәм почмак урыннар КИРӘК

Түләү килешү буенча. Тәкъдимнәр җибәрү өчен адрес: Казан, Университет урамы, 13. 44—2—2

Галиәсгар Камал исмендәге

Татар Дәүләт Академия театры

12 нче гыйнварда көндез (талон 93)

ГАЕПСЕЗДӘН ГАЕПЛЕЛӘР

Кич (талон 94), шулай ук 13 һәм 14 нче гыйнварда (талоннар: 95, 96)

КЫЮ КЫЗЛАР

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

12 һәм 13 нче гыйнварда М. Ю. Лермонтовның тууына 125 ел тулуга багышланган юбилей спектакльләре

МАСКАРАД

Бүген талон 75.

13 нче гыйнварда талоннар белән кертелми. **Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.** Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Тулысынча яңа программа

Москва 4 нче труппасының гастрольләре

Бөтен труппа катнаша.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

„ЗАГОТКОНЬ“

ның Татарстан республика конторасы

1940 нчы елда атлар бирү буенча дәүләт учреждениеләреннән һәм колхозлардан

ЗАЯВКАЛАР АЛА

һәм алар белән шушы ел 20 нче гыйнварга кадәр

ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ

Бер үк вакытта, **„Заготконь“ нәселле атлардан: җиңелгә җигү атлары һәм эш атлары сатып ала.** 49—2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 11-45, 1-45, 3-45, 5-45, 7-45 һәм 9-45 тә.	Көндез 10 сәгаттә **ҺАВА ПОЧТАСЫ** һәм башка сеансларда **УКЫТУЧЫ**
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	**УКЫТУЧЫ** Көндез 10 сәгаттә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда **МИТЬКА ЛЕЛЮК** Кич **УКЫТУЧЫ**
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	**СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН**
„ПИОНЕР“ 11, 2, 4, 5-45 8 һәм 10-15 тә	Көндезге сеансларда **ПАРТИЗАН КЫЗЫ** Кичке сеансларда **БӨЕК ГРАЖДАНИН** (икенче сериясе) Көндез 1 сәгаттә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс
„РОТ-ФРОНТ“ 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	**Бөек бүләк**
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	**ТАУ МАРШЫ**

Татарстан АССР Осоавиахимының дегазацион отряды дезинфекция һәм дезинсекция эшләре үткәрү, шулай ук агач материалларын йогышсызландыру (антисептирование) эшләре буенча дәүләт, промышленность һәм кооператив оешмалары белән

ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ БАШЛАДЫ.

Казан, Пионер урамы, 7. Тел. 44—40. 2641—2—1 **Администрация.**

Казандагы, шулай ук районнардагы совхозларда эшләү өчен **өлкән бухгалтерлар, өлкән бухгалтер урынбасарлары, бухгалтерлар һәм хисапчылар кирәк.** Казан, Козье бистәсе, Октябрь урамы, 30, Татарстан АССР Совнаркомы янындагы шәһәр тирәсе хуҗалыклар тресты. Телефон 15—00. 2574—2—2

Даими эшкә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ БОНДАРЬЛАР һәм КАССИРЛАР кирәк. Хезмәт хакы прогрессив тәртиптә түләнә. Казан, Аргы Устье, 2 нче нефтебаза. 28—2—2

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2481 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 163.